РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЯТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫЯТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

22 ноября 2018 года | № 9

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Кыят авыл җирлегендә гражданнардан
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге Уставы белән җирле референдумда (гражданнар җыенында) 2018 елның 19 ноябрендәге 11-6 номерлы карарны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге башкарма комитеты,

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адрес буенча, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адрес буенча бастырып чыгарырга һәм ТР, Буа районы, Кыят авылы, Яшьләр ур., 2; ТР, Буа районы, Кыят авылы, Яшьләр ур., 9. йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка хәбәр итәргә кирәк.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

ТР Буа муниципаль районы Кыят авыл
җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе М.М. Храмова

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Кыят авыл җирлеге
2018 елның 22 ноябреннән № 9
Башкарма комитет карары буенча
1нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен әлеге тәртип билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү, җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кыят авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан 2019 елның 31 декабренә кадәр башкарыла.

3. Бер тапкыр түләү турында белдерү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән, шулай ук имза астына тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салым акчалары Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчерүләрен гамәлгә ашыру юлы белән (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша сылтама буенча https://uslugi.tatarstan.ru/ башкарыла.

6. Касса ордерының квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактынраслый торган документлар булып тора.

7. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Кыят авыл җирлеге
2018 елның 22 ноябреннән № 9
Башкарма комитет карары буенча
2 нче кушымта

ИЗВЕЩЕНИЕ (Хәбәрнамә) № _______________
Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге бюджетына үзара салым акчасын бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф.И.А.и ______________________________________________________
Адресы:
____________________________________________________________
Нигез _________________________________________________________
Сезгә ____________________кадәр ___________________чараларын тормышка ашыру өчен бер тапкыр ____________ сум күләмендә түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк:_________________________________________________
Алучы Банк БИК ____________________________________
Сч. № _________________________________
Алучы Сч. № ________________________________________
ИНН ________________________________________
КПП ________________________________________
КБК _______________ ОКАТО __________________
Билгеләнгән
түләү______________________________________________________________________

Җитәкче _________________ _______________________________________
М.У. (имза) (имзаны тутырып язу)

- - - - - - - - - - - - - - - - - Өзү сызыгы- - - - - - - - - - - - - -

Извещение (Хәбәрнамә) № _________________
________сум күләмендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге бюджетына үзара салым акчасын бер тапкыр түләү турында
Түләүченең Ф.И.А.и. ______________________________________________________
Адресы:
________________________________________________________________________
Алды «__» ______________ 20__ ел. ____________________________________
(түләүче имзасы)

*Искәрмә. Түләүчегә хәбәрнамә шәхсән тапшырылса, өзмә туплама тутырыла һәм башкарма комитетта кала.*